КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 16 май г.Казань № 324

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кечкенә сөт парклары территориясендә сөт юнәлешендәге мөгезле эре терлекләр тоту фермалары төзүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 19 февраль, 140 нчы карары белән расланган Кечкенә сөт парклары территориясендә сөт юнәлешендәге мөгезле эре терлекләр тоту фермалары төзүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кечкенә сөт парклары территориясендә сөт юнәлешендәге мөгезле эре терлекләр тоту фермалары төзүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 19 февраль, 140 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 23 август, 891 нче, 2023 ел, 17 июль, 850 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Кечкенә сөт парклары территориясендә сөт юнәлешендәге мөгезле эре терлекләр тоту фермалары төзүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларына субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктның беренче абзацында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалкан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары,» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2 пунктның дүртенче абзацында «16дан 23 башка кадәр яисә» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.6 пунктта «2020» саннарын «2023» саннарына алмаштырырга;

1.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Субсидия турында мәгълүмат «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасы бердәм порталының (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.»;

1.8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«үзлегеннән җайга салына торган оешмага кертелгән фермалар төзегәндә төзелеш контроле үткәрү һәм әлеге эшне башкаручы белгечләр Төзелеш өлкәсендәге белгечләрнең илкүләм  реестрына кертелгән шарт белән.»;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Сайлап алуда катнашучы заявка каралган һәм килешү төзелгән даталарга түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы барлыгы турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый;

Берләшкән Милләтләр Оешмасы (алга таба - БМО) уставының VII бүлегендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында БМО Куркынычсызлык Советы яки БМО Куркынычсызлык Советы карарлары белән махсус оештырылган органнар

тарафыннан төзелә торган террорчылык оешмалары һәм террорчылар белән яки массакүләм юк итү коралын тарату белән бәйле оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмау;

әлеге Тәртипнең 1.1 пунктында күрсәтелгән максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә акча алмый;

«Чит ил йогынтысында булган затлар эшчәнлеген контрольдә тоту турында» 2022 елның 14 июлендәге 255-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чит ил агенты түгел;

сайлап алуда катнашучының бердәм салым счетында Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм иминият кертемнәре түләү бурычы булмау яки Россия Федерациясе Салым кодексының 47 статьясындагы 3 пункты белән билгеләнгән күләмнән артмый;

сайлап алуда катнашучының башка субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычы, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләр буенча үз вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычы булмау;

юридик зат булган сайлап алуда катнашучы үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашкан юридик затка башка юридик затны кушу рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процессы билгеләнмәү, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау, ә индивидуаль эшмәкәр булган сайлап алуда катнашучы үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмау.»;

2.3 пунктта:

дүртенче - җиденче, унберенче  абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

ундүртенче – унҗиденче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«капиталь төзелеш объекты төзелешенең смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерү өлешендә капиталь төзелеш объектының проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе яки проект документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе күчермәсе (икедән армаган катлы булган, гомуми мәйданы 1 500 кв.метрдан артмаган  аерым торучы капиталь төзелеш объектлары өчен);

фермалар төзүгә рөхсәт күчермәсе;

үз-үзен җайга сала торган оешма белән һәм әлеге эшне башкаручы белгечләр Төзелеш өлкәсендәге белгечләрнең милли реестрына кертелгән очракта фермалар төзегәндә башкарылган эшләрнең сыйфатына һәм күләмнәренә төзелеш контролен гамәлгә ашыруны күздә тоткан шартнамәнең күчермәсе;

җыелма смета  исәп-хисабы күчермәсе;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«локаль смета исәп-хисаплар күчермәләре;

төзелеш-монтаж эшләрен башкаруга подряд шартнамәләре күчермәләре;

төзелеш контролен гамәлгә ашыручы оешма белән проект документациясенең башкарылган эшләренә оешма белән туры килүенә килештерелгән «Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт» дигән КС-2 нче статистик форма буенча белешмә кәгазьләре күчермәләре;

«Башкарылган эшләр һәм чыгымнар кыйммәтләре турында белешмә кәгазе» дигән КС-3 нче статистик форма буенча белешмә кәгазьләре күчермәләре;

2023 елдан да иртәрәк булмаган чорда башкарылган эшләр өчен түләүне раслаучы түләү йөкләмәләре күчермәләре;

фермалар төзегәндә объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт;

заявка биргән көнгә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган вакытта бирелгән хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларында фермага төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

Заявка һәм аңа теркәлә торган документлар бер папка (том) итеп тегелгән, һәр битенә номерлар сугылган, сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең үз имзасы белән имзаланган һәм сайлап алуда катнашучы мөһере белән таныкланган булырга тиеш.

Һәр документ төгәл итеп басылган булырга тиеш. Документларда чистарту һәм төзәтүләр рөхсәт ителми, сайлап алуда катнашучы җитәкчесенең үз имзасы белән имзаланган һәм сайлап алуда катнашучы мөһере белән (булган очракта) таныкланган төзәтмәләрдән тыш.

Идарәгә заявкалар кабул итү срогы башланганчы яисә заявкаларны кабул итү срогы тәмамланганнан соң (шул исәптән почта элемтәсен оештыру аша) кергән заявкалар теркәлми, шул исәптән алга таба сайлап алулар уздырганда да да, каралмый һәм Идарә күрсәтелгән заявкалар кергән көннән алып 10 эш көне эчендә аларны почта элемтәсе хезмәте аша сайлауда катнашучыларга теркәүдән баш тартуның сәбәпләрен күрсәтеп кире кайтара.

Теркәлгән заявкалар үзләренә беркетелгән документлар белән сайлап алуда катнашучыларга кире кайтмый һәм Идарәдә саклана.»;

2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме (С) (сумда) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$\mathrm{C} = \sum_{\mathrm{k}=1}^{\mathrm{r}} (\mathrm{Z_k} \times 0{,}7),$$

монда:

k - 24 һәм аннан да күбрәк баш мөгезле эре терлек асрау фермалары;

r - 24 һәм аннан да күбрәк баш мөгезле эре терлек асрау фермалары саны;

Zk – 2023 елдан да иртәрәк булмаган башкарылган эшләрне КС-2 номерлы форма буенча кабул итү турындагы актларга кертелгән 24 баш һәм күбрәк кадәр эре мөгезле терлек асрау фермалары төзүгә бәйле төзелеш, монтаж һәм башка төр эшләр өчен түләүнең факттагы чыгымнары (өстәлгән бәягә салым түләүгә чыгымнардан тыш), сум;

Субсидиянең иң чик күләме 24 баш һәм аннан да күбрәк мөгезле эре терлек тоту буенча бер фермага исәпләгәндә - 5,0 млн. сум.»;

түбәндәге эчтәлекле $3.3^1$ пункт өстәргә:

«$3.3^1$. Юридик зат булган субсидияне алучыны кушылу, кушу яисә үзгәртеп кору рәвешендә үзгәртеп төзегәндә, килешүгә, хокук варисы булган юридик затны

килешүдә күрсәтеп, мәҗбүри рәвештә затны алмаштыру өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәрешләр кертелә.

Россия Федерациясе Граждан кодексының 23 статьясындагы 5 пунктының икенче абзацы нигезендә крестьян (фермер) хуҗалыгы башлыгы буларак эшчәнлекне гамәлгә ашыручы индивидуаль эшкуар булган, үз хокукларын башка гражданга «Крестьян (фермер) хуҗалыгы турында» 2003 елның 11 июнендәге 74-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы нигезендә тапшыра торган субсидия алучының эшчәнлеге туктатылганда килешүгә, хокук варисы булган башка зат килешүендә якларны күрсәтеп, затны үзгәртү өлешендә килешүгә өстәмә килешү төзү юлы белән үзгәрешләр кертелә.»;

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Субсидия алучы Идарәгә түбәндәгеләрне тапшыра:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән бертип форма нигезендә хисап кварталыннан соң килүче айның 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, ферманы проект куәтенә кадәр комплектлаганнан алып биш ел дәвамында субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе турында хисап;

әлеге Тәртипнең 1.3 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән субсидия бирү шартларын үтәү турында хисап, ел саен 1 февральгә Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча субсидия бирелгән елдан башлап алты ел дәвамында.»;

түбәндәге эчтәлекле 4.2 пункт өстәргә:

«4.2. Министрлык әлеге Тәртипнең 4.1 пункты нигезендә субсидия алучы тарафыннан тапшырылган хисапларны мондый хисаплар тапшырылган көннән алып 30 эш көненнән артмаган срокта тикшерә һәм кабул итә.»;

5.1 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткечләренә ирешүне субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чара тәмамлану фактын чагылдыручы вакыйгаларны (контроль нокта) мониторинглау Министрлык тарафыннан нәтиҗәләргә ирешүне мониторинглауны уздыру тәртибендә билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча уздырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин